РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь, 2020 ел Кукмара ш. № 27

«Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетын төзү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 26 номерлы Кукмара район Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәнең 3.3 пунктына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

«Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетын төзү турында» 2005 елның 22 декабрендәге 26 номерлы Кукмара район Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмәнең 3.3 пунктына (Кукмара муниципаль район Советының 2015 елның 30 мартындагы 08 номерлы, 2019 елның 15 июлендәге 233 номерлы карарлары редакциясендә), түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«15) полиция участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев